

Мордовия Главасы Артём Алексеевич Здунов игълан иткән Сәламәтлек елына багышлап Дубенка районынын Ломат авылында хатын-кызлар командалары арасында «Киез итекле хоккей» ярышы узган.

Совет чорында киез итекле хоккейны малайлар һәр ишегалдында диярлек уйнаганнар, ә бvген бу уен vзенен икенче тууын кичерә.       Киез итекле хоккей кагыйдәләре традицион уеннан аерылмый диярлек. Топ аерма шунда: шайба урынына зур теннис очен туп кулланыла, ә тимераяклар-коньки урынына уенчылар киез итек-валенки кия.

Ярыш Ломат авылы жирлегендә vткән. Кочкурово авыл жирлеге, Дубенка район мәдәният йорты, Дубенка район китапханәсе хезмәткәрләре – бер команда булса, ә икенчесендә - Ломат авылы администрациясе житәкчесе Колесанова Наталья Александровна, Яхеева Венера Фәрит кызы, Шабанова Гелдюсә Шакир кызы, Рахметуллова Нажия Ихсан кызы, Мусина Юлия Шамиль кызы, Мураkаева Мәзидә Якуб кызы иде. «Киез итекле хоккей» ярышы судьясы Раиль хазрәт Мусин булса, анын ярдәмчесе улы Абдулла иде.



Хоккей азарты кvнел ачу белән очрашканда, кышкы уеннар атмосферасына чумыла. Бу уникаль ярыш сезгә ин якты хис-кичерешләр бvләк итә - карда туп очен дәртле корәштән алып гадәти булмаган киез итекләр киеп колvгә кадәр. Биредә сугунын тизлеге һәм тогәллеге генә тvгел, ә барлык катнашучыларны берләштерәчәк команда рухынын гажәеп тойгысы да моһим. Уен-нын һәр мизгеле житезлеккә һәм чыдамлыкка онытылмас

сынау. Шулай итеп хоккей матчы гадәти булмаган һәм кvнелле vткән. Барлык катнашучылар да унай хис-кичерешләр һәм лаеклы бv- ләкләр алган.
Топ жинvчеләр бvләге Ломат авылы хатын-кызлары командасы яулаган.

Ярышлардан сон барлык уенчыларны милли камыр ризыклары, тәмле пылау, кайнар чәй белән сыйлаганнар. Аннары Ломат авылы музеенда вакытларын файдалы һәм кvнелле vткәргәннәр: татар милли мәдәнияты тарихына чумганнар.
Сәламәт яшәv рәвешен популярлаштыру, авылда массакvләм спортны vстерv һәм хоккейга тарту максатларында,  Ломат авылында «Киез итекле хоккей» спорт-кvнел ачу чарасы оештырылган. Әлеге спорт торе елдан-ел массакvләм характер алыр һәм ерак vткәндәге халык традицияләрен торгызыр дип ометләнәбез.

**Наилә НАСЫРОВА**